Нурмөхәммәтова Р.С., КФУ,

филология фәннәре кандидаты

**Ризык атамаларында матди һәм рухи мәдәниятнең чагылышы**

Тарихта мәгълүм бер гыйбарә бар: үз милли традицияләрен хәтерләгән һәм саклаган халык гомерле һәм көчле була. Халыкны яшәтә торган шундый гореф-гадәтләрнең берсе ризык әзерләү һәм ашау культурасына бәйле.

Ризык – матди мәдәниятнең бер өлешен тәшкил итә һәм ул һәрбер мәдәнияттә халыкның һөнәр-кәсебен, тормыш-яшәү шартларын, тәҗрибәсен, матди байлыгын, табын муллыгын һ.б. чагылдыра. Ризык, беренче чиратта, барлык җан ияләренең табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерә, ягъни аларны тукландыра, көч-энергия бирә. Әмма кешене, хайваннардан аермалы буларак, ризыкның әлеге төп функциясеннән тыш, элек-электән башка яклары да кызыксындырган: ул аны табынга ничек бирү, тәмен генә түгел, бәлки тышкы кыяфәтен дә күзгә ятышлы итү турында да уйланган. Шул рәвешчә, кеше гади генә әйберләрдән төрле-төрле ашамлыклар әзерли башлаган.

Ю.С.Степанов фикеренчә, “мәдәнияттә “чиста матди” һәм “чиста рухи” күренешләр юк” [8: 717]. Күп кенә ризыклар да халыкның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләренә, йолаларга бәйле була, алар төрле бәйрәмнәрнең төп компонентларына әверелә. Шуңа күрә ризыкларда матди һәм рухи мәдәният элементлары туплану табигый.

Татар халкы гомер-гомердән иген-тарылы, ипи-чәйле, якты чырайлы булган. Ата-бабаларыбыз аш-суга милләтебезнең эстетик һәм рухи асылын билгеләүче бер сыйфат итеп караганнар, тырышып иген иккәннәр, мал-туарны күп асраганнар [3: 3]. Шунлыктан татар милли ризыклары арасында камыр ризыклары, итле-яшелчәле ашамлыклар төп урынны алып тора.

Татарлар камырга һәрчак зур әһәмият биргәннәр, аны оста итеп ясаганнар, төче һәм ачы, баллы һәм гади, сыек һәм куе, каты камырдан эчлек белән яисә эчлексез генә төрле ризыклар пешергәннәр [10: 161-162]. Шундый ризыклар арасында *бәлеш* аерым игътибарга лаек. Бу – эченә төрле ашамлыклар (ит, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.) салып, мичтә табада пешерелгән камыр ашы [9:

102]. Татарлар аны элек-электән яратып әзерләгәннәр, төрле эчлекләр салганнар, төче һәм ачы камырдан пешергәннәр.

Этимологиясенә килгәндә, Р.Әхмәтьянов аны *бәһале аш* тезмәсеннән килеп чыккан дип аңлата, әмма шуңа охшаш сүзләрнең – ашамлык атамаларының фарсы телендә дә булуын искәртә. Шулай ук бу сүзнең башка халыкларда булуына да мисаллар китерә: удмурдча *бальыш*, мари телендә *палыш, бӓлыш, бӓлеш*, чувашча *палĕш, пелĕш*, русча *беляш*, ә себер татарларында *бәләш* [2: 40]. Ф.Баязитова хезмәтендә дә бу сүзнең татар теленнән күрше халыкларга да керүе күрсәтелә: башкорт телендә *бәлеш,* чувашча *пелеш*, мари халкында *палыш* [3: 213].

Ә.Юсупова *бәлеш* сүзенең XIX гасыр сүзлекләрендә дә теркәлүен ачыклый [10: 162]. Бу сүз XX-XXI гасырда басылган татарча-русча сүзлекләрнең (алга таба – ТРС) барысында да диярлек урын алган: 1913 елгы сүзлектә بالان بەلشى – пирогъ съ калиной (ТРС 1913, 49); بەلش – круглый пирог (ТРС 1927, 64); bələş – круглый пирог (ТРС 1931, 45); Большой пирог (национальный) (ТРС 1950, 89); Балеш (большой круглый пирог с начинкой) (ТРС 1966, 90); Бэлиш (национальное кушанье) (ТРС 1988, 66); Бэлеш; пирог (ТРС 2007, 219). Әйтелгәннәр әлеге ризыкның һәр чорда популяр булуы хакында сөйли.

*Бәлеш* сүзе кергән ризык атамалары гаять күп һәм аларның компонентларында ризыкның матди эчтәлеге дә күренә: үрдәк бәлеше составында үрдәк ите булуны күздә тота, дөгеле бәлештә бер компонент дөге була. “Табада без коймак пешерәбез, кабартма, сумса, өчпочмак, *бәлеш*: ярма, кабак, дөге, бәрәңге, әнис салып, ит турап бәлеш пешерәбез. *Каз бәлеше* була, *кабак бәлеше*, каздан *баш-аяк бәлеше* була,” – дип яза М.Мәһдиев “Торналар төшкән җирдә” әсәрендә. Бәлешләрне сыер, сарык һәм һәртөрле кош итеннән, балыктан, ярма һәм яшелчәләрдән әзерләргә була, аларны биек итеп тә, тәбәнәк итеп тә, вак кына итеп тә ясыйлар. Биек бәлеш, гадәттә шулпалы була, аны “зур бәлеш” дип тә йөртәләр. Тәбәнәк бәлешне “юка бәлеш” диләр. Ю.Әхмәтҗановның “Татар халык ашлары” хезмәтендә бәлешнең бик күп

төрләрен пешерү серләренә өйрәтелә [1: 115-124, 328-333]: *шулпалы ит бәлеше, шулпалы каз бәлеше, баш-аяк бәлеше, үрдәк бәлеше, көзге чебеш бәлеше, карабодай бәлеше, итле дөге бәлеше* һ.б. Бу бәлешләр гадәттә табынга таба белән чыгарыла, монда татар халкының элек-электән килгән гореф-гадәтләре дә, ашау культурасы белән бәйле үзенчәлекләре дә чагыла: табынга табада бирелгән ризык озак вакыт суынмый; бер табадан ашау гаилә әгъзаларының бердәмлеген күрсәтә, мондый ризыкны һәркем үз вакыты белән ашый алмый, ул бөтен гаиләнең бергә җыелуын таләп иткән. Бәлеш тышкы яктан күпләргә таныш “пирог”ка охшаган, әмма аның эчлеге дә, табынга кисеп бирү рәвеше дә үзгә. Иң мөһиме: ул һәрвакыт түгәрәк итеп ясала, бу эчтә кайнар һаваның әйләнеп йөрүенә мөмкинлек бирә. Тыгыз итеп ябылган камыр капкач эчтәге табигый хуш исләрнең тышка чыгуына киртә булып тора, нәкъ менә шул сәбәпле әлеге ризык телне йотарлык тәмле була торгандыр да инде. Бәлешләрнең түгәрәк итеп пешерелүе дә күпмедер дәрәҗәдә символик мәгънә белдерә булса кирәк: “түгәрәк, әйләнә” формасы күпчелек халыкларда кояш, яктылык, яхшылык, бөтенлек, камиллек мәгънәләренә ия. Ул геометрик фигуралар арасында иң универсаль форма. Татарларда теләк белдергәндә түгәрәк сүзе еш кулланыла бит: *түгәрәк тормыш, түгәрәк бәхет, түгәрәк табын* һ.б. Бәлешне шулай ук чуенда, чүлмәктә дә пешергәннәр була, аларын табынга зур савытка салып китергәннәр, хәзер исә тәлинкәләргә бүлеп ашыйлар.

Юка итеп пешерелә торган бәлешләрне (*юка ит бәлеше, җимешле дөге бәлеше, яшел суган бәлеше, кәбестә бәлеше, кабак бәлеше, балык бәлеше, бәрәңге бәлеше* һ.б.) һәркемгә өлешләп бүлеп китерәләр, болары берникадәр соңрак пешерелә башланган булырга тиеш, чөнки бу очракта савыт-саба күплеге таләп ителә, ашау һәм табынга ризык бирүнең берникадәр европалашуы күренә. Бәлешләрне кечкенә (*вак бәлеш, шулпалы вак бәлеш, дөгеле вак бәлеш, каз итеннән вак бәлеш, үпкә-бавырдан вак бәлеш* һ.б.) итеп пешерү тәҗрибәсе дә соңрак килгәндер: чөнки мондый ризыкларга он-камыр аеруча күп кирәк.

“Татарның әүвәлге төп сые – чәй” дип яза К.Фукс [7: 25]. Татар халкы чәйне бик күптән эчә башлаган, әмма чәй популяр булган башка көнчыгыш халыкларыннан аермалы буларак, татарларда чәй табыны аерым бер ашауны алыштыра, чөнки чәй янына күп төрле камыр ризыклары бирелә. Кунакларга камыр ашлары белән чәй эчертү элек-электән иң яхшы сый саналган. Чәй ашлары арасында һәртөрле җиләк-җимеш эчлекләре белән пешерелгән баллы бәлешләр дә куела: *алма бәлеше, чия бәлеше, балан бәлеше, кара җиләк бәлеше, нарат җиләге бәлеше, эремчек бәлеше, корт бәлеше* һ.б. Болар алда әйтеп үтелгән “пирог”ларга күбрәк охшаган һәм хәтта татар телендә пирог һәм бәлеш сүзләре синоним буларак та кулланыла. *Барыбыз өчен дә татлы, тансык аш:/ Шомырт пирогы, балан бәлеше...* дип яза шагыйрә Ф.Гыйззәтуллина да (“Уңыш бәйрәме”).

Бәлешләрнең татар халкында популяр булуы аларның татарлар яши торган һәр төбәктә пешерелүендә дә күренә. Җирле төбәкләрдә бу төр ризыкларның атамаларында берникадәр аермалар саклана. Ф.Баязитова хезмәтендә бирелгән бәлеш атамалары [3: 212-224]: *астыған бәлеш* – кура җиләге бәлеше (себер диалектлары), *ачыли бәлеш* – ачы камырның эченә нәрсә дә булса салып пешерелгән бәлеш (темников сөйләше), *гүрләк бәлеше* – кура җиләк бәлеше (ләмбрә сөйләше), *каwын бәлеш* – кабак бәлеше (мәләкәс сөйләше), *қузбәлеш* – эченә ваклап төелгән чикләвек салып пешерелгән бәлеш (әстерхан татарлары сөйләше), *көрөс бәлеш* – дөге бәлеше (себер диалектлары), *нуғай бәлеше* – ит белән дөгедән пешерелгән биек бәлеш (әстерхан татарлары сөйләше), *төпсез бәлеш* – табага ит, бәрәңге, май салып, өстенә камыр ябып пешерелә торган бәлеш (минзәлә сөйләше) һ.б.

Бәлешләр төрле бәйрәмнәрнең, йолаларның да аерылгысыз атрибутын тәшкил итә. Мисал өчен, *баш-аяк бәлешен* күз көне казлар суйгач, каз өмәсендә пешергәннәр; аулак өйләрдә һәрвакыт бәлеш пешерелгән һәм хәтта “бәлеш урлау” дигән шаян йола да киң таралган була. Кайбер йолалар белән бәйле бәлеш атамаларын җирле сөйләшләр материалыннан күрергә була (мисаллар Ф.Баязитованың атап үтелгән хезмәтеннән алынды): *бәби бәлеш* – бәби туена

пешереп алып килгән бәлеш (тау ягы, тархан сөйләше), *кейәү бәлеш* – кияүне сыйлау өчен пешерелә торган бәлеш (себер диалектлары), *кыдаги бәлеше* – туй вакытында кияүнең яки кызның эти-әниләре пешергән бәлеш (кузнецк сөйләше), *қыз бәлеше* – егет өеннән кыз ягына җибәрелгән бәлеш (әстерхан татарлары сөйләше), *оло бәлеш* – туй өчен пешерелгән ит белән дөге бәлеше (казан арты, дөбьяз сөйләше), *ырын аш бәлеше* – аулак өйдә пешерелгән бәлеш (чистай сөйләше) һ.б.

Әдәби әсәрләрдә дә *бәлеш* сүзе шактый еш очрый һәм күбрәк көндәлек ризык атамасы буларак кулланыла. Мәсәлән, Гали белән Фазыйл өйләреннән ак күмәч кисәкләре, *бәлеш* калдыклары чыгарып бирделәр (Г.Ибраһимов “Кызыл чәчәкләр”). Тәүдә танауны симез елкы шулпасының буы кытыклап алды, бераз торгач *бәлеш* көегенең исе килеп сугылды (М.Кәрим “Ишеткәннәр, күргәннәр...). Ит исе чыккан тәбәнәк өйгә килеп кергәч, хәзрәтнең күзе чыбылдык артындарак посып, *бәлеш* майлап йөргән яшь киленгә төште (М.Мәһдиев “Кеше китә – җыры кала”). Бәлеш-коймаклар, җимеш сулары китерелеп торган табында чөкердәшеп утыручыы апаларның ул аяк очларын гына күрә (М.Галиев “Сүзсез дога”). Зәрия мунча якты, Гөлия *бәлеш*кә ит-бәрәңге турады (Н.Гыйматдинова “Мәхәббәттә гөнаһ бар”). Кара әле, *бәлеш*ен ашап утыр әле (М.Кәбиров “Елмаю”).

Шагыйрьләр дә бу сүзгә битараф түгел: *Бәлеш салам, белгәнемне укып,/ Каз итеннән, кайнар, шулпалы./ Чөкердәшеп чәйләп утырыйк соң,/ Күршеләрем дәшим, туктале,* – дип яза Э.Шәрифуллина (“Тормыш яме”).

*Бер киявем – Минзәләдә, / – Кил, сөтле сыерыбыз, – ди, – / Бәлеш тә пилмән, пәрәмәч / Булыр гел сыебыз, – ди,* – дип җырлана мәгълүм бер җырда (“Яшәсен кияүләрем”, М.Хөсәен сүзләре, З.Хәбибуллин көе).

*Бәлеш* сүзе мәкальләрдә дә күп очрый. Өч томлык “Татар халык мәкальләре” җыентыгында бу сүз кергән иллеләп мәкаль теркәлгән. Аларда әлеге ризыкның барлык матди хасиятләре ачылган, шул ук вакытта әлеге мәкальләргә яшерелгән рухи мәдәният элементларын да тоемлау кыен түгел, аларда татар халкына хас кунакчыллык, хезмәт сөючәнлек, муллыкка омтылу,

дус-иш белән гомер итүгә өстенлек бирү кебек сыйфатлар чагыла. Мисал итеп китерелгән мәкальләр, һәрвакыттагыча, читләтеп кенә үгет-нәсихәт бирә, безнең очракта, тәмле белән кызыктырып, яман сыйфатлардан арынырга өнди.

1. Бәлеш – затлы ризык, аны кунакларга, мәҗлесләргә, туйга пешерәләр: *Көн дә бәлеш, көн дә туй булмый* (9688) – күңел ачып кына яшәп булмый; *Ике бәлеш, бер пәрәмәч кияүләрнең азыгы* (9797) – кияү – кадерле кеше, аңа сый-хөрмәтнең дә иң яхшысы; *Әлдермешкә туй төшкән чак, мичтә бәлеш пешкән чак* (9679) – туйга иң затлы ризыклар хәзерләнә; *Көн дә бәлеш, көн дә туй, көн дә сагыш, көн дә уй* (37393) – шатлык белән сагыш янәшә; *Белешең булса, баргач бәлеш ашарсың* (20663) – татарлар кергән кешене сыйламыйча озатмый; *Таныгым таныш, табамда – бәлеш* (27127) – таныш-белешкә – һәрчак сый-хөрмәт һ.б.

2. Бәлешне пешерү өчен шактый гына хәлле булу кирәк, чөнки ул күп төрле азык-төлек булуны таләп итә: *Бәлешнең авызы чалыш, хәзер аның турында сөйләргә ярамый, имеш* (15437). Әлеге гыйбарә азык-төлеккә авыр елларда әйтелгән; *Бәлеш бәкләр ашы...* (15637); *Муллаларча, дөнья – бер шурпалы бәлеш, имеш* (Г.Тукай) (18758) – дөньяны һәркем үз хәленнән торып аңлый дигәнгә ишарә; *Йокы – ярлы бәлеше* (19050) – иренгән кешенең йокыдан кала байлыгы да, ризыгы да юк һ.б.

3. Бәлеш пешерерлек хәле булган кешенең дуслары, әшнәләре күп була яисә хәлле, ризыклы кеше янына барысы да җыела: *Бәлеш булса, белеш табыла* (15436). Төрдәше: *Бәлешең булса, белешең күп була; Бәлеш янында кем дә белеш* (15441); *Белеш барда бәлеш бар* (20666) һ.б.

4. Бәлеш пешерү авыр эш, аны теләсә кем, аеруча ялкаулар булдыра алмый: *Йокы – ялкауның бәлеше* (1442) – ялкау булсаң, иң тәмле сыең йокы булыр; *Ашамасам ашамам, бу бәлешне ясамам!* (15433) – эшләргә иренгән, ашаудан да баш тарта; *Бәлеш пешергән – ботка төшергән* (15440) – бәлеш пешерәм дип йөреп аягы (боты) талган (чөнки бәлеш пешерү бик мәшәкатьле эш); *Чибәр бәлеш пешергән – чибәр булган, чи булган* (15451) – бәлешне сырлау, матурлау гына җитми, иң мөһиме – ашарлык булу, пешеп җитү; *Йоклаган*

*өлештән калган, соң килгән бәлештән калган* (19014) – һәр эшне вакытында эшләргә кирәк һ.б.

5. Бәлеш – тәмле ризык, аны һәркемнең ашыйсы килә: *Үзе үлә ятса да, бәлештән авыз итәсе килә* (19630) – тәмле ризык үләргә яткан кешене дә кызыктыра. Бәлеш төбе аеруча тәмле: *Бәлешнең төбе – кызларның теле* (15438) – бәлеш төбе иң тәмле җире санала; *Бәлешнең төбе – чананың түре* (15439) – иң кадерле кунакка, кешегә бәлешнең тәмле җире, чананың яхшы урыны һ.б.

6. Бәлеш – тәмле, туклыклы аш, һәркайсы авыр эштән соң шундый ризык ашау зарур: *Эшнең төбе – бәлеш* (1402). Яки: *Эшнең соңы – бәлеш.* Монда бәлеш хезмәт өчен тиешле түләүне дә аңлата һ.б.

*Бәлеш* кешенең тискәре якларын тәнкыйтьләү өчен чагыштыру элементы буларак алына, бу очракта кайберәүләрнең тәмле ризык ашауга караганда начар гадәтләрне үз итүе күпертелә: *Бәлештән калсам да, гайбәттән калмам!* (29590); *Кайнар бәлештән калсам калырмын, аулак сүздән калыр хәлем юк!* (29661); *Тәмле бәлештән калыр идем, шыпырт сүздән калмас идем* (29674) һ.б.

Кайбер мәкальләрдә ашау (ризык – бәлеш) һәм эшләү капма-каршы куела: *Бетмәгән эш – пешмәгән бәлеш* (221); *Эш майлы бәлеш түгел* (601); *Бәлеш ашарга яраткан авыз бәлшәеп калучан була, ди* (15435); *Бәлеш белән гыйлем бергә җыелмас* (*Г.Тукай)* (29950); *Эш майлы бәлеш түгел* (36062) һ.б.

Фразеологизмнарда *бәлеш* сүзе күбрәк тискәре күренешләрне тасвирлаганда кулланыла: *аяклы бәлеш* – тән-бәдән байлыгыннан башка рухи сыйфаты булмавына яки бик тә ашауга бирелгән булуына ишарә белән кайбер симез, көр хатын-кызлар турында әйтелә (4: 121); *бәлеш авыз* – корыга авызын җәеп торган, булдыксыз кеше турында; елак бала турында (4: 201); *бәлеш имгәге (козгыны, үләте)* – бәлеш артыннан бәлеш ашаучылар; элеккеге ишаннардан, түрә-начальниклардан, байлардан көлеп әйтү (4: 201); *бәлеш төбе* – йомшак табигатьле кеше турында (4: 202); *яңак бәлеше ашату* – яңагына суккалап, бәргәләп алу (5: 304); *үпкә бәлеше* – үпкәчән кеше турында (5: 340) һ.б. Әлеге фразеологизмнарның да бәлешнең төп матди характеристикаларына (зур, майлы, йомшак, тәмле һ.б) нигезләнүен сизү кыен түгел.

Шул рәвешчә, ризык атамаларында халкыбызның күңел һәм рухи байлыгы да, матди хуҗалыгы, тырышлыгы, эшчәнлеге, уңганлыгы да, тормыш тәҗрибәсе дә ачык чагыла. Шуңа күрә рухи һәм матди мәдәниятның кисешү ноктасы булган ризык атамаларын өйрәнү тел белемендә соңгы елларда көчәеп килгән лингвокультурология фәне үсешенә зур өлеш кертәчәк.

Әдәбият

1. Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары / Ю.Ә.Әхмәтҗанов. – Казан: Раннур, 1999. – 464 б.

2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

3. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы / Ф.С.Баязитова. – Казан: Дом печати, 2007. – 480 б.

4. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

5. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 366 б.

6. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда / Н.С.Исәнбәт. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

7. Карл Фукс. Казан һәм Казан төбәге: Гыйльми хезмәтләр, документлар, истәлекләр, эзләнүләр / Карл Фукс. – Казан: Җыен, 2008. – 448 б.

8. Степанов Ю.С. Константы: Словарь русской культуры: изд-е 3-е, испр. И доп. / Ю.С.Степанов. – М.: Академический проект, 2004. – 992 с.

9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

10. Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века / А.Ш.Юсупова. – Казань: Изд-во Казанск.гос. ун-та, 2008. – 410 с.